ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» октября 2020 ел № 352

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль
бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе
булган Үтәгән авылында мәктәпкәчә белем бирү программасын
гамәлгә ашыруны туктату турында

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы үтенечнамәсен карап, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе булган Үтәгән авылында мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кыскаруга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 04 февралендәге 60 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе булган Үтәгән авылында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын һәм аны гамәлгә ашыруны туктатырга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Үтәгән авылы, Мәктәп ур., 3 адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне кабул итү һәм тапшыру акты буенча алырга һәм оператив идарә хокукын теркәүне туктату буенча гамәлләр кылырга тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорына Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль

районы, Үтәгән авылы, Мәктәп ур., 3 адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына тапшырырга һәм оператив идарә хокукын теркәүне туктату буенча гамәлләр кылырга.

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгына әлеге карар буенча оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 01 октябренән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**